ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.02.2022 Казан ш. № 9-3/кс-2022

«ТКХ (инженерлык челтәрләре)» муниципаль унитар предприятиесе өчен эчәргә яраклы суга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ санлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 санлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э санлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «ТКХ (инженерлык челтәрләре)» муниципаль унитар предприятиесе (алга таба – «ТКХ (инженерлык челтәрләре)» МУП) өчен, әлеге карар кушымтасы нигезендә, календарь буенча бүлеп, эчәргә яраклы суга тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән башлап 2022 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «ТКХ (инженерлык челтәрләре)» муниципаль унитар предприятиесенә иректле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 санлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хабибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
09.02.2022 № 9-3/кс-2022
карарына кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «ТКХ (инженерлык челтәрләре)» МУП өчен эчәргә яраклы суга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүче оешма исеме | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|
| | | __________________ № ____карар үз көченә кергән көннән башлап 2022 елның 30 июненә кадәр | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр |
| | Әлмәт муниципаль районы | | |
| 1 | «ТКХ (инженерлык челтәрләре)» МУП* | | |
| 1.1 | Әлмәт, Аппак, Баграж-Никольский, Борискино, Бота, Васильевка, Югары Акташ, Югары Мактама, Елхово, Ерсубайкино, Кичү, Кичүчат, Клементейкино, Кузайкино, Колшәрип, Урман-Кәләй, Мәмәт, Миңлебай, Түбән Абдул, Яңа Кәшер, Яңа Нәдер, Яңа Никольский, Яңа Троицкий, Сәрән, Иске Михайловка, Иске Суркино, Сөләй, Ямаши, Ямаш авыл җирлекләре | 32,42 | 32,42 |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге